Татарстан Республикасы исеменнән

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**КАРАРЫ**

**гражданин А.В. Орлов шикаятенә бәйле рәвештә «"Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренең 8 пунктындагы «а» пунктчасының икенче абзацының конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре 2019 елның 25 декабре

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында «"Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне

торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренең 8 пунктындагы «а» пунктчасының икенче абзацының конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданин А.В. Орлов шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив нигезләмәнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Э.М. Мостафина мәгълүматын, яклар — гражданин А.В. Орлов, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле — Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы юридик бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе Ф.М. Мөхәммәдиева аңлатмаларын, суд утырышына дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле үтенечнамәсе буенча чакырылган белгеч — Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының торак сәясәте бүлеге башлыгы Н.К. Вильданова аңлатмаларын, суд утырышына чакырылган: Татарстан Республикасы Президенты вәкиле — Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсенең закон проектлары эшләү бүлеге баш киңәшчесе Р.В. Сидаков, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы урынбасары — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең социаль законнар бүлеге мөдире Д.И. Мәхмүтов, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкиле — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы А.Б. Гревцов, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Югары суды судьясы Э.С. Каминский, Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Арбитраж судының суд практикасын анализлау һәм гомумиләштерү бүлеге башлыгы Р.Р. Шкаликов, Татарстан Республикасы Прокуроры вәкиле — Татарстан Республикасы прокуратурасы Федераль

законнар үтәлешенә күзәтчелек итү идарәсенең норматив хокукый актларның законлылыгына күзәтчелек итү бүлеге башлыгы А.Р. Вәлиәхмәтов, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән — Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппаратының гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлеге әйдәп баручы консультанты Р.Р. Мингалиев чыгышларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин А.В. Орлов «"Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренең (алга таба шулай ук — Кагыйдәләр) 8 пунктындагы «а» пунктчасының икенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Шикаять белдерелә торган Кагыйдәләрнең 8 пунктындагы «а» пунктчасының икенче абзацы нигезендә күпбалалы гаилә һәм (яки) аерым гаилә әгъзалары тарафыннан аларның милек хокукында булган торак урыны (торак урыннар) яисә әлеге гражданнарның торак урынга гомуми уртак милек хокукындагы өлеше алынган очракта (алга таба — күпбалалы гаилә һәм (яки) аерым гаилә әгъзалары тарафыннан аларның милек хокукында булган торак урыны алыну), субсидия күләмен исәпләү өчен кулланыла торган торак урынның гомуми мәйданы күләме әлеге Кагыйдәләрнең 7 нче пунктында күрсәтелгән норматив буенча билгеләнгән торак урынның гомуми мәйданы һәм күпбалалы гаилә социаль наем шартнамәләре, социаль

файдаланудагы торак фондның торак урыннары наем шартнамәләре буенча яши торган һәм (яки) күпбалалы гаиләнең һәм (яки) аерым гаилә әгъзаларының милек хокукында булган торак урыннарның (алар яшәгән торак урыннар санитария нормаларына һәм яшәү кагыйдәләренә туры килгән очракта) һәм алынган торак урынның (торак урын милекчеләренең килешүендә билгеләнгән яки торак урынга уртак милек хокукындагы өлешләренә пропорциональ исәпләнгән, аерым гаилә әгъзасына туры килә торган торак урынга милек хокукындагы өлешенең) кушылган гомуми мәйданы арасындагы аерма буларак билгеләнә; әлеге граждан-хокукый алыш-бирешләр күпбалалы гаиләгә сертификат биргәнгә кадәр булган чор, әмма ким дигәндә биш ел өчен исәпкә алына.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларның күчермәләреннән аңлашылганча, гражданин А.В. Орлов 2013 елдан бирле хатыны һәм балалары белән торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәптә торалар һәм, күпбалалы гаилә буларак, гражданның Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алу өчен субсидия (алга таба шулай ук — субсидия) алуга хокукын раслый торган исемле таныклык булып торучы сертификат алу хокукына ия дип күрсәтә. Шул ук елда мөрәҗәгать итүче үзенең милек хокукында булган гомуми мәйданы 66,2 кв. метрлы фатирын саткан.

Фатирын сатканда ул шул вакытта гамәлдә булган, аталган субсидия күләмен исәпләгәндә граждан тарафыннан башкарылган граждан-хокукый алыш-бирешләрне исәпкә алу шартларын үз эченә алмаган хокукый җайга салуга таянган. Гражданин А.В. Орлов, шикаять белдерелә торган норма Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 27 июнендәге 443 номерлы карары белән кертелгән дип билгеләп үтә. Әмма аның гаиләсен 2018 елга торак сертификатларын алучылар исемлегенә керткәндә, әлеге алыш-биреш субсидия күләмен исәпләгәндә хокук куллану органы тарафыннан исәпкә алынган.

Шуңа бәйле рәвештә, аның фикеренчә, дәгъва белдерелә торган норма

Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килә, чөнки хокук куллану практикасында бирелә торган мәгънәсе буенча аны шикаять белдерелә торган норма үз көченә кергәнче граждан-хокукый алыш-бирешләр кылган гражданнарга карата кулланырга рөхсәт итә, ягъни аның нигезләмәләренә кире көч бирергә юл куя, бу хокукый дәүләт шартларында һич тә ярамый.

Мөрәҗәгать итүче шулай ук, әлеге норма торак урыннарны читләштерү буенча барлык граждан-хокукый алыш-бирешләрне, ягъни шул исәптән торак шартларын начарайтуга китермәгәннәрен, ә торак шартларын яхшырту максатларында башкарылганнарын да исәпкә алырга мөмкинлек бирә дип билгеләп үтә.

Моннан тыш, гражданин А.В. Орлов шикаять белдерелә торган норманың күпбалалы гаиләгә сертификат биргәнгә кадәр булган чор, әмма ким дигәндә биш ел өчен граждан-хокукый алыш-бирешләрне исәпкә алу буенча хокук куллану органының анда каралган бурычы өлешендә билгесезлек күрә. Шулай итеп, ул, дәгъва белдерелә торган норма граждан-хокукый алыш-бирешләр исәпкә алынырга мөмкин булган конкрет чорны билгеләми, әлеге мәсьәләне чишүне хокук кулланучының каравына калдыра, ул биш ел эчендә дә, биш елдан артык чорда да әлеге алыш-бирешләрне исәпкә алырга мөмкин дип билгели.

Бәян ителгәннәр нигезендә мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Конституция судыннан «“Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренең 8 пунктындагы «а» пунктчасының икенче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенең 13, 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 38 (беренче һәм өченче өлешләр),

54 (беренче өлеш), 55 статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә Татарстан Республикасы — сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт; закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген социаль һәм мөлкәти хәленә һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; расачыл, милли һәм башка билгеләр буенча гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүнең теләсә кайсы рәвеше я аларга өстенлекләр билгеләү тыела; гаилә, ана булу, ата булу, балачак һәм картлык дәүләт яклавында; дәүләт гаилә турында, ананың һәм баланың сәламәтлеген тәэмин итү һәм балаларны тәрбияләү турында кайгырта; һәркемгә балаларны тәрбияләү өчен һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә; һәркем торакка хокуклы; беркем дә торагыннан нигезсез мәхрүм ителә алмый; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торак төзелешен хуплыйлар, торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, «“Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренең 8 пунктындагы «а» пунктчасының икенче абзацы түбәндәге дәрәҗәдә әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора:

— хокук куллану практикасында бирелә торган мәгънәсе буенча шикаять белдерелә торган норма үз көченә кергәнче башкарылган күпбалалы гаилә һәм (яки) аерым гаилә әгъзалары тарафыннан үзләренеке булган торак урынын читләштерү буенча граждан-хокукый алыш-бирешләргә, субсидия күләмен билгеләү өчен алына торган торак урынның гомуми мәйданы күләмен исәпләгәндә аңа кире көч бирү һәм аның гамәле кагылу мөмкинлеген калдыра;

— күпбалалы гаилә һәм (яки) аерым гаилә әгъзалары тарафыннан үзләренеке булган торак урынын читләштерү буенча граждан-хокукый алыш-бирешләрне, шул исәптән торак шартларын яхшырту максатларында башкарылган, әмма шул ук вакытта торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыкны югалту өчен нигез булып тормаганнарын да исәпкә алырга мөмкинлек бирә;

— субсидия күләмен билгеләү өчен алына торган торак урынның гомуми мәйданы күләмен исәпләгәндә күпбалалы гаилә һәм (яки) аерым гаилә әгъзалары тарафыннан үзләренеке булган торак урынын читләштерү буенча граждан-хокукый алыш-бирешләр исәпкә алына торган конкрет чорны билгеләми.

2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәләр социаль яклау һәм торак законнары өлкәсенә кагыла. Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлешнең «ж» һәм «к» пунктлары) нигезендә социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклау, шулай ук торак законнары Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагында. Россия Федерациясенең һәм Россия

Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла; Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары федераль законнарга каршы килә алмый (Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясы, 2 һәм 5 өлешләр).

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның 26.3 статьясындагы 2 пунктының 24 пунктчасы нигезендә балалары булган гаиләләргә (шул исәптән күпбалалы гаиләләргә, ялгыз ата-анага) социаль ярдәм мәсьәләләрен хәл итү Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнарының уртак карамактагы мәсьәләләр буенча әлеге органнар тарафыннан Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары исәбеннән мөстәкыйль гамәлгә ашырыла торган (федераль бюджеттан кергән субвенцияләрдән тыш) вәкаләтләренә керә. Шулай ук әлеге Федераль закон белән шул каралган: Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары исәбеннән (федераль бюджеттан максатчан чыгымнарны гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе субъекты бюджетына тапшырыла торган финанс чараларыннан тыш) гражданнарның аерым категорияләре өчен социаль ярдәм күрсәтүнең һәм социаль булышуның өстәмә чараларын федераль законнарда күрсәтелгән хокукны билгели торган нигезләмәләрнең булу-булмавына бәйсез рәвештә билгеләргә хокуклы. Аталган вәкаләтләрне финанслау Россия Федерациясе субъектының бурычы булып тормый, мөмкинлек булганда гамәлгә ашырыла һәм федераль бюджеттан өстәмә акча бүлеп бирү өчен нигез булып тормый (26.3-1 статьяның өченче һәм дүртенче өлешләре).

«Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 1992 елның 5 маендагы 431 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы белән Россия Федерациясе составындагы республикалар хөкүмәтләренә,

крайларның, өлкәләрнең, автоном берәмлекләрнең, Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләренең башкарма хакимият органнарына, регионның социаль-икътисади һәм демографик үсешендә милли һәм мәдәни үзенчәлекләрне исәпкә алып, күпбалалы һәм өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ гаиләләр категорияләрен һәм күпбалалы гаиләләр өчен социаль ярдәм чараларын билгеләү йөкләнгән булган (1 пунктның «а» һәм «б» пунктчалары).

«Күпбалалы гаиләләрнең торак шартларын яхшырту буенча өстәмә чаралар турында» 2001 елның 17 мартындагы 216-ПУ номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы белән ата-ана белән бергә яшәүче һәм үз гаиләләрен кормаган биш һәм аннан күбрәк баласы булган торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләр торак урыннарны чираттан тыш алу хокукына ия гражданнар категориясенә керә дип билгеләнгән.

Күрсәтелгән норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне, ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны, шулай ук ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан үзләренә беркетелгән торак урыннары булмаган затларны торак белән тәэмин итү чаралары турында» 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарны кабул иткән, аңа Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән үзгәрешләр кертелгән, шулай ук дәгъва белдерелә торган Кагыйдәләр расланган.

Шулай итеп, Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләрен раслап, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенә федераль һәм республика законнары нигезендә бирелгән һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 102 (4 пункт) һәм 103 статьяларының үзара бәйле нигезләмәләренә таянган вәкаләтне дөрес гамәлгә ашырган, алар буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты социаль тәэминат

өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен үткәрүдә катнаша, Татарстан Республикасы территориясендә федераль законнарның һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының, Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үтәлешен тәэмин итә, Татарстан Республикасының бөтен территориясендә үтәү мәҗбүри булган карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара.

3. Татарстан Республикасын социаль дәүләт дип игълан итеп (13 статья), Татарстан Республикасы Конституциясе шуны беркетә: гаилә, ана булу һәм балачак дәүләт яклавында, дәүләт гаилә турында, ананың һәм баланың сәламәтлеген тәэмин итү һәм балаларны тәрбияләү турында кайгырта (38 статья, беренче һәм өченче өлешләр); һәркемгә балаларны тәрбияләү өчен һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә (54 статья, беренче өлеш). Мәгънәләре буенча тиңдәш гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясе, шул исәптән аның 7, 38 (1 өлеш) һәм 39 (1 өлеш) статьялары белән билгеләнгән.

Россия Федерациясе Конституция Суды карарларында билгеләп үтелгәнчә, социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклауны Россия Федерациясе һәм аның субъектларының уртак карамагына кертеп (72 статья, 1 өлешнең «ж» пункты), Россия Федерациясе Конституциясе гражданнарның теге яки бу категорияләренә бирелә торган мондый яклауның конкрет ысулларын һәм күләмнәрен билгеләми. Әлеге мәсьәләләрне хәл итү закон чыгаручының аерым хокукы булып тора, ул Россия Федерациясе Конституциясенең 38 һәм 39 статьялары белән беркетелгән хокукларны гамәлгә ашыру гарантияләрен билгеләгәндә гаилә һәм балаларны социаль яклау чараларын, аларны дифференциацияләү критерийларын сайлап алуда, күрсәтелү шартларын һәм тәртибен регламентлаштыруда җитәрлек дәрәҗәдә ирекле эш итә; ул шулай ук аларның күрсәтелү формаларын (ысулларын) сайлап алырга һәм үзгәртергә хокуклы (2009 елның 10 ноябрендәге 17-П номерлы Карар, 2010 елның 9 ноябрендәге 1439-О-О номерлы Билгеләмә).

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән торак сатып алу өчен түләүсез нигездә субсидия бирү рәвешендәге социаль ярдәм чарасы ата-аналар белән яшәгән һәм үз гаиләләрен булдырмаган биш һәм аннан да күбрәк баласы булган торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне (күпбалалы гаиләнең үз гаиләләрен корган балаларына никахлары теркәлгән яки үз баласы (балалары) булган балигъ балалар керә) (Кагыйдәләрнең 4 пунктындагы «а» пунктчасы) торак белән тәэмин итү буенча өстәмә ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән.

Үзенең хокукый табигате буенча әлеге социаль ярдәм чарасы, Татарстан Республикасы Конституция суды элегрәк билгеләп үткәнчә, социаль тәэмин итүнең мәҗбүри төренә керми һәм, асылда, күрсәтелгән гаиләләрнең тормыш дәрәҗәсен күтәрүнең өстәмә алымы булып тора; Татарстан Республикасы күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен субсидия бирү шартларын һәм тәртибен, шул исәптән республика бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, мөстәкыйль билгели (2011 елның 5 октябрендәге 44-П номерлы, 2019 елның 30 маендагы 83-П номерлы карарлар, 2011 елның 11 октябрендәге 13-О номерлы билгеләмә).

3.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күпбалалы гаиләләргә өстәмә социаль ярдәм күрсәтү чарасын бирү мәсьәләсен җайга салып, шактый дискрециягә ия, әмма ул тигезлек, гаделлек һәм хокук һәм ирекләрне чикләүнең ярашлылыгы конституциячел принциплары белән, хокукый җайга салуның билгеләнеш таләпләре белән, шул исәптән ул тудыра торган хокукый нәтиҗәләрдә, шулай ук гомуми тармакара хокукый принциплар белән чикләнгән, шуларның берсе — вакыт дәвамында норматив хокукый актның гамәлдә булу принцибы.

Россия Федерациясе Конституция Суды үз карарларында берничә тапкыр күрсәткәнчә, законның вакыт дәвамында гамәлдә булуының гомуми (төп) принцибы булып аны гамәлгә керткәннән соң барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагылуы тора, һәм бары тик закон чыгаручы гына тиешле

нормалар гамәлгә кергәнче барлыкка килгән фактларга һәм алар тудырган хокукый нәтиҗәләргә яңа нормаларны таратырга, ягъни законга кире көч бирергә хокуклы. Моның белән бергә гражданнарның гарантияләрне һәм ташламаларны күздә тоткан хокукларын билгели торган яисә үзгәртә торган яңа нормаларның вакытында һәм затлар даирәсе буенча гамәлләр кагыйдәләрен билгеләү аларга Россия Федерациясе Конституциясе таләпләрен, шул исәптән тигезлек принцибыннан килеп чыккан таләпләрне үтәп гамәлгә ашырылырга тиеш (19 статья, 1 һәм 2 өлешләр), ул гражданнарга, социаль тәэминатка хокукны да кертеп, хокук һәм ирекләрне гамәлгә ашырганда дискриминациянең барлык рәвешләреннән яклауны гарантияли (2005 елның 18 гыйнварындагы 7-О номерлы; 2017 елның 19 декабрендәге 2978-О номерлы, 2019 елның 26 мартындагы 732-О номерлы һ.б. билгеләмәләр).

Россия Федерациясе Торак кодексының 6 статьясы нигезләмәләре буенча торак турындагы законнар актлары кире көчкә ия булмый һәм аларны гамәлгә кертканнән соң барлыкка килгән торак мөнәсәбәтләренә карата кулланыла (1 өлеш); торак турындагы законнар актының гамәли көче бары тик турыдан-туры шул актта каралган очракларда гына аны гамәлгә керткәнче барлыкка килгән торак мөнәсәбәтләренә кагылырга мөмкин (2 өлеш).

Китерелгән хокукый җайга салу торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрнең торак сатып алу өчен субсидия алу хокукын гамәлгә ашыру өлкәсендә барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә дә кагыла.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 27 июнендәге 443 номерлы карары белән Кагыйдәләрнең 8 пунктындагы «а» пунктчасы субсидия күләмен билгеләү өчен алына торган торак урынның гомуми мәйданы күләмен исәпләү тәртибен үзгәртүне күздә тоткан дәгъва белдерелә торган абзац белән тулыландырылган. Әлеге үзгәрешләр нигезендә субсидия күләмен билгеләгәндә күпбалалы гаиләнең һәм (яки) аерым гаилә әгъзаларының милек хокукында булган торак урыннарның читләштерелүе

буенча күпбалалы гаиләгә сертификат биргәнгә кадәр булган чор, әмма ким дигәндә биш ел өчен барлык граждан-хокукый алыш-бирешләр исәпкә алына башладылар.

Шул ук вакытта, дәгъва белдерелә торган норма кертелгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 27 июнендәге 443 номерлы карарының эчтәлеген анализлаудан күренгәнчә, бу исә яңа хокукый җайга салуның үз көченә кергәнче барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагылуы турындагы нигезләмәне билгеләми.

Бәян ителгәннәрне һәм әлеге карарның Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru 2016 елның 1 июлендә рәсми басылып чыгу һәм  рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач, ягъни 2016 елның 11 июлендә үз көченә керү фактын игътибарга алып, Татарстан Республикасы Конституция суды ул кире көчкә ия түгел һәм, шул исәптән, яңа җайга салу үз көченә кергән көнгә кадәр барлыкка килгән дәвамлы хокук мөнәсәбәтләренә карата да аны куллану мөмкинлеген күздә тотмый дигән нәтиҗәгә килә.

Мондый алым Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә тулысынча туры килә, ул гражданнарның хокукый хәленә тискәре йогынты ясый торган гамәлдәге хокукый җайга салуга үзгәрешләр кертү гражданнарның законга һәм дәүләт гамәлләренә ышанычын хуплау принцибы саклану белән бергә алып барылырга тиеш, ул хокукый җайга салуның нигезле тотрыклылыгын саклап калуны һәм гамәлдәге нормалар системасына законсыз үзгәрешләр кертүгә юл куелмауны күз алдында тота; тиешле хокукый мөнәсәбәтләрдә катнашучылар нигезле чикләрдә үз халәтенең нәтиҗәләрен  алдан күрү мөмкинлегенә ия булырга һәм үзенең рәсми танылган статусының, алган хокукларының үзгәрешсез калуына, аларның дәүләт тарафыннан яклануының тәэсирле булуына, ягъни гамәлдәге законнар нигезендә алган хокукның хакимиятләр тарафыннан ихтирам ителәчәгенә һәм тормышка ашырылачагына ышанычы булырга тиеш дип берничә тапкыр ассызыклады (2001 елның 24 маендагы 8-П номерлы,

2011 елның 20 июлендәге 20-П номерлы, 2016 елның 15 февралендәге 3-П номерлы; 2013 елның 16 июлендәге 1071-О номерлы, 2015 елның 22 декабрендәге 2991-О номерлы һ.б. билгеләмәләре).

Шулай итеп, дәгъва белдерелә торган норма карала торган аспектта Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килми, чөнки гамәлдәге хокукый җайга салу системасында үзенең конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча аңа кире көч бирү һәм субсидия күләмен билгеләү өчен алына торган торак урынның гомуми мәйданы күләмен исәпләгәндә күпбалалы гаилә һәм (яки) аерым гаилә әгъзалары тарафыннан үзләренеке булган торак урынын читләштерү буенча шикаять белдерелә торган норма үз көченә кергәнче башкарылган граждан-хокукый алыш-бирешләргә аның гамәле кагылу мөмкинлеген күздә тотмый.

3.2. Карала торган социаль ярдәм чарасын билгеләп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенең хокук чыгару вәкаләтләре кысаларында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак җирле үзидарә органнарында исәптә торучы күпбалалы гаиләләрне торак урыны алу өчен субсидия алу хокукына ия күпбалалы гаиләләр исемлегенә кертү максатларына туры килергә тиешле берничә шартны караган, шулай ук аның күләмен исәпләү механизмын билгеләгән.

Шулай, Кагыйдәләрнең 7 пункты нигезендә субсидия күләмен исәпләп чыгару өчен торак урынның гомуми мәйданы нормативы гаиләнең һәр әгъзасына 18 кв. метр тәшкил итә. Кагыйдәләрнең 8 пунктындагы «а» пунктчасы күпбалалы гаиләләр өчен субсидия күләме — күпбалалы гаилә биләгән торак урынның (алар яшәгән торак урыннар санитария нормаларына һәм яшәү кагыйдәләренә туры килгән очракта) гомуми мәйданын тотып калып, һәм тиешле чорга вәкаләтле орган тарафыннан расланган Татарстан Республикасында торакның 1 кв. метр гомуми мәйданының уртача кыйммәтеннән чыгып күрсәтелгән норматив буенча билгеләнә дип ачыклый.

Шул ук вакытта әлеге пунктның дәгъва белдерелә торган икенче

абзацы күпбалалы гаилә һәм (яки) аерым гаилә әгъзалары тарафыннан аларның милек хокукында булган торак урыны алынган очракта, Кагыйдәләрнең 7 нче пунктында күрсәтелгән норматив буенча билгеләнгән торак урынның гомуми мәйданы һәм (яки) күпбалалы гаиләнең һәм (яки) аерым гаилә әгъзаларының милек хокукында булган торак урыннарның һәм читләштерелгән торак урынның кушылган гомуми мәйданы арасындагы аерманы ачыклау юлы белән субсидия күләмен исәпләү өчен кулланыла торган торак урынның гомуми мәйданы күләмен исәпләү тәртибен билгели.

Субсидия күләмен исәпләүнең китерелгән тәртибе үз мәгънәсе һәм максатчан билгеләнеше буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 21 мартындагы 153 номерлы карары белән расланган «Россия Федерациясе гражданнарын арзан һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Торак белән тәэмин итүдә һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү» ведомство максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында Дәүләт торак сертификатларын чыгару һәм гамәлгә ашыру кагыйдәләренең 16 (2) пунктында каралган тәртипкә охшаш һәм торак урыннарына мохтаҗ дип танылган гражданнарның торак урыннары белән гражданлык-хокукый алыш-бирешләрнең хокукый нәтиҗәләрен беркетүче Россия Федерациясе Торак кодексы нормалары белән туры килә. Шулай, Россия Федерациясе Торак кодексының 57 статьясындагы 8 өлеше нигезендә гражданга социаль яллау шартнамәсе буенча торак урын бирелгәндә, биләнә торган торак урыннарның күләмен киметүгә яисә аларны читләштерүгә китергән гамәлләр һәм торак урыннарга карата башкарылган граждан-хокукый алыш-бирешләр исәпкә алына.

Россия Федерациясе Конституция судының кайбер карарларында әйтелгән хокукый позицияләре эчтәлегеннән күренгәнчә, Россия Федерациясе Конституциясеннән килеп чыга торган социаль гаделлек принцибына нигезләнгән Россия Федерациясе Торак кодексының 57 статьясындагы 8 өлеше нигезләмәләре дәүләт һәм муниципаль торакны

нормативтан тыш нигезсез бирүне булдырмауга юнәлдерелгәннәр (2013 елның 24 сентябрендәге 1480-О номерлы, 2014 елның 25 сентябрендәге 2080-О номерлы, 2015 елның 17 февралендәге 376-О номерлы һ.б. билгеләмәләр).

Федераль законнарның китерелгән нигезләмәләрен исәпкә алып дәгъва белдерелә торган норманы системалы анализлау шуны күрсәтә, ул үзенең максатчан билгеләнеше буенча субсидия күләмен исәпләүнең оештыру-исәпкә алу кагыйдәләрен билгеләүгә юнәлдерелә, аны кертү чынлыкта аңа мохтаҗ булган күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен мондый субсидия күләмен гадел исәпләүне гамәлгә ашыру, шулай ук алар ягыннан мөмкин булган явыз нияттән файдалануны булдырмау зарурлыгына бәйле. Шул ук вакытта гамәлдәге хокукый җайга салу кысаларында әлеге норма Россия Федерациясе Граждан кодексының 10 статьясындагы 5 пункты белән үзара бәйләнештә кулланылырга тиеш, аның нигезендә хокук мөнәсәбәтләрендә катнашучыларның намуслылыгы һәм аларның гамәлләренең акылга ярашлы булуы күздә тотыла. Моннан күренгәнчә, шикаять белдерелә торган норма үзенең хокукый табигате буенча күпбалалы гаилә һәм (яки) аерым гаилә әгъзалары тарафыннан башкарылган торак урыны мәйданын киметүгә яисә аны читләштерүгә китергән торак шартларын ясалма начарайтуга юнәлтелгән алдан уйланган гамәлләрне ачыклау максатларында, граждан-хокукый алыш-бирешләрне бәяләүгә юнәлдерелгән. Шул ук вакытта, күпбалалы гаилә һәм (яки) аерым гаилә әгъзалары тарафыннан булган торак урыны читләштерелгән һәм үз торак шартларын яхшырту өчен аннан соң зуррак мәйданлы торак урыны алынган очракта, әгәр шуның белән бергә гаилә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ статусын югалтмаса, субсидия күләме бары тик яңа алынган торак урынын исәпкә алып кына саналырга тиеш.

Дәгъва белдерелә торган норманы башкача аңлау күпбалалы гаиләләрнең торак хокукларын яклау өлкәсендә норматив җайга салуның конституциячел әһәмиятле максатлары белән туры килмәслек һәм нигезсез

булыр иде һәм котылгысыз рәвештә Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан гамәлгә ашырылган хокукый җайга салуның нәтиҗәлелеген аның чын ихтыярына каршы сизелерлек киметүгә китерер иде.

Шулай итеп, Кагыйдәләрнең 8 пунктындагы «а» пунктчасының икенче абзацы нигезләмәләре Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килми, чөнки үзенең конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча, биләгән торак урынның мәйданын киметү максатларында граждан-хокукый алыш-бирешләр ясаган күпбалалы гаилә һәм (яки) аерым гаилә әгъзалары тарафыннан башкарылган гамәлләрне объектив бәяләүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән һәм үзеннән-үзе торак шартларын начарайтуга китермәгән торак урыннарны читләштерү буенча гражданлык-хокукый алыш-бирешләрне исәпкә алуны күз алдында тотмыйлар, ә киресенчә, торак шартларын яхшырту максатыннан башкарылган, ләкин шул ук вакытта күпбалалы гаиләнең торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыгын югалту өчен нигез булмаган гамәлләр исәпкә алына.

Кагыйдәләрнең күрсәтелгән нигезләмәләрен әлеге Карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәдә Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килми дип тану белән карала торган хокукый җайга салуны камилләштерү барышында аңа субсидия күләмен исәпләгәндә кулланыла торган күпбалалы гаилә һәм (яки) аерым гаилә әгъзалары тарафыннан аларның милек хокукында булган торак урыны алыну буенча граждан-хокукый алыш-бирешләрнең нигезен ачыклый торган үзгәрешләр кертүгә юнәлтелгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләте кире кагылмый. Мондый җайга салу Кеше хокуклары буенча Европа Судының хокукый позициясенә туры килә, ул, хокукый билгеләнеш принцибын үтәү зарурлыгын таләп итеп, үз карарларында берничә тапкыр күрсәткәнчә, закон Кеше хокукларын һәм төп ирекләрен яклау турындагы конвенциядә билгеләнгән барлык законнарның җитәрлек дәрәҗәдә төгәл формалаштырылуын һәм юридик ярдәм кирәк булган очракта затка аның теге яисә бу гамәлләре нинди нәтиҗәләргә бәйле була алуын күзаллау

мөмкинлеген бирүне таләп итә торган стандартка туры килергә тиеш (2007 елның 24 маендагы «Игнатов (Ignatov) Россиягә каршы» эше; 2007 елның 24 маендагы «Владимир Соловьев (Vladimir Solovyev) Россиягә каршы» эше буенча карарлар).

3.3. Мөрәҗәгать итүченең дәгъва белдерелә торган нормада субсидия күләмен билгеләү өчен алына торган торак урынның гомуми мәйданы күләмен исәпләгәндә күпбалалы гаилә һәм (яки) аерым гаилә әгъзалары тарафыннан үзләренеке булган торак урынын читләштерү буенча граждан-хокукый алыш-бирешләр исәпкә алынган конкрет чорның булмавы турындагы дәлилләренә карата Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгеләрне билгеләп үтәргә кирәк дип саный.

Федераль дәрәҗәдә дә, республика дәрәҗәсендә дә күрсәтелгән чорны билгеләү тәртибенә кагылышлы таләпләр куелмаган. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, үзенә бирелгән норматив-хокукый вәкаләтләр кысаларында эш итеп, аталган граждан-хокукый алыш-бирешләр күпбалалы гаиләгә сертификат биргәнгә кадәр булган чор, әмма ким дигәндә биш ел өчен исәпкә алына дип билгеләгән.

Дәгъва белдерелә торган норманың анда билгеләнгән срок өлешендә юридик конструкциясе асылда Россия Федерациясе Торак кодексының 57 статьясындагы 8 өлеше нигезләмәләренә охшаш, алар нигезендә, биләнә торган торак урыннарның күләмен киметүгә яисә аларны читләштерүгә китергән гамәлләр һәм торак урыннарга карата башкарылган граждан-хокукый алыш-бирешләрнең гражданга социаль яллау шартнамәсе буенча торак урын бирелгәнгә кадәр Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән чордагылары исәпкә алына, ул чор биш елдан да ким булмаска тиеш. Шул ук вакытта китерелгән федераль норма социаль наем шартнамәсе буенча гражданинга торак урын бирелүгә кадәрге чорның түбән чиген генә императив рәвештә беркетә, аның өчен югарыда күрсәтелгән гамәлләр һәм алыш-бирешләр исәпкә алына, шул ук вакытта конкрет вакыт аралыгы Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнәчәген күздә тота.

Нәкъ менә Россия Федерациясе Торак кодексының күрсәтелгән нормасын үтәү йөзеннән «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 27 статьясындагы 2 өлешендә республика закон чыгаручысы конкрет вакыт аралыгы билгеләгән — биш ел, шул вакыт эчендә биләнә торган торак урыннарның күләмен киметүгә яисә аларны читләштерүгә китергән гамәлләр һәм торак урыннарга карата башкарылган граждан-хокукый алыш-бирешләр исәпкә алына.

Ләкин Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән хокукый җайга салу аны Россия Федерациясе Торак кодексы нигезләмәләре белән охшашлык буенча алга таба конкретлаштыру мөмкинлеген күздә тотмый. Шуңа бәйле рәвештә дәгъва белдерелә торган нормада кулланылган «ким дигәндә биш ел өчен» формулировкасы, аның сүзгә-сүз аңлатмасыннан чыгып, хокук кулланучыга граждан-хокукый алыш-бирешләрнең исәпкә алыну вакытын мөстәкыйль билгеләргә мөмкинлек бирә торган вариатив характерга ия. Башка сүзләр белән әйткәндә, хокук куллану органы үз ихтыяры белән әлеге алыш-бирешләрнең биш ел эчендәгеләрен дә, биш елдан артык вакыт эчендәгеләрен дә исәпкә алырга мөмкин.

Татарстан Республикасы Конституция суды, мондый алымны нигезле дип танырга ярамый, чөнки дәгъва белдерелә торган норма эчтәлегенең билгесезлеге хокук куллану процессында чикләнмәгән каралуга юл куя һәм законсызлыкка, димәк — тигезлек һәм закон өстенлеге принципларының бозылуына китерә дип саный.

Алай гына да түгел, мондый алым норматив нигезләмәләргә карата куела торган ачыклык һәм каршылыксызлык таләпләре белән туры килми, аларда законның гамәлдә булу механизмы тиешле хокук мөнәсәбәтләре субъектларына конкрет норматив нигезләмәләр эчтәлегеннән яисә норматив нигезләмәләрнең күзгә күренеп торган үзара бәйләнешендә булган

системадан чыгып аңлаешлы булырга тиешлеге, чөнки конституциячел тигез хокуклылык хокукый норманы барлык хокук кулланучылар тарафыннан бертөрле аңлау һәм аңлату шарты белән генә тәэмин ителергә мөмкин булуы күздә тотыла (Россия Федерациясе Конституция Судының 2013 елның 27 июнендәге 15-П номерлы, 2013 елның 23 декабрендәге 29-П номерлы, 2014 елның 22 апрелендәге 12-П номерлы һ.б. карарлар).

Шулай итеп, «"Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренең 8 пунктындагы «а» пунктчасының икенче абзацы, әлеге мәсьәләне хәл итүне хокук кулланучының каравына калдырып, субсидия күләмен билгеләү өчен алына торган торак урынның гомуми мәйданы күләмен исәпләгәндә күпбалалы гаилә һәм (яки) аерым гаилә әгъзалары тарафыннан үзләренеке булган торак урынын читләштерү буенча граждан-хокукый алыш-бирешләр исәпкә алынган конкрет чорны билгеләми торган дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституциясенә, аның 28 (беренче өлеш) һәм 55 статьяларына туры килми.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Кагыйдәләрнең дәгъва белдерелә торган нормасына югарыда аталган җитешсезлекне бетерә торган һәм анда билгеләнгән хокукый җайга салуны ирекле куллану мөмкинлеген юкка чыгара торган тиешле үзгәрешләр кертергә кирәк.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71 һәм 73 статьяларына,

104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. «“Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренең 8 пунктындагы «а» пунктчасының икенче абзацын гамәлдәге хокукый җайга салу системасында үзенең конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча аңа кире көч бирү һәм субсидия күләмен билгеләү өчен алына торган торак урынның гомуми мәйданы күләмен исәпләгәндә күпбалалы гаилә һәм (яки) аерым гаилә әгъзалары тарафыннан үзләренеке булган торак урынын читләштерү буенча шикаять белдерелә торган норма үз көченә кергәнче башкарылган граждан-хокукый алыш-бирешләргә аның гамәле кагылу мөмкинлеген күздә тотмый торган дәрәҗәдә; үзеннән-үзе торак шартларын начарайтуга китермәгән торак урыннарны читләштерү буенча гражданлык-хокукый алыш-бирешләрне исәпкә алуны күз алдында тотмыйлар, ә киресенчә, торак шартларын яхшырту максатыннан башкарылган, ләкин шул ук вакытта күпбалалы гаиләнең торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыгын югалту өчен нигез булмаган дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. «“Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән

тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренең 8 пунктындагы «а» пунктчасының икенче абзацын, әлеге мәсьәләне хәл итүне хокук кулланучының каравына калдырып, субсидия күләмен билгеләү өчен алына торган торак урынның гомуми мәйданы күләмен исәпләгәндә күпбалалы гаилә һәм (яки) аерым гаилә әгъзалары тарафыннан үзләренеке булган торак урынын читләштерү буенча граждан-хокукый алыш-бирешләр исәпкә алынган конкрет чорны билгеләми торган дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танырга.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Кагыйдәләрнең дәгъва белдерелә торган нормасына югарыда аталган җитешсезлекне бетерә торган һәм анда билгеләнгән хокукый җайга салуны ирекле куллану мөмкинлеген юкка чыгара торган тиешле үзгәрешләр кертергә кирәк.

3. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазифаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

4. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясы нигезендә әлеге Карар «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылып чыгарга тиеш.

**№ 87-П**

**Татарстан Республикасы Конституция суды**